| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2019 Казан шәһәре № 3-5/э

Нигездә бер кулланучыга хезмәт күрсәтүче «Нижнекамскшина» гавами акционерлык җәмгыяте өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә аерым тарифлар һәм «КАМАЗ-Энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2020-2024 елларга аерым тарифлар билгеләү турында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең "Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә зарури тулай табышны озак вакытлы индексацияләү методын кулланып билгеләнә торган тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр, әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә, нигездә бер кулланучыга хезмәт күрсәтүче «Нижнекамскшина» гавами акционерлык җәмгыяте өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә календарь буенча бүленгән аерым тарифлар билгеләргә.

2. «Нижнекамскшина» гавами акционерлык җәмгыяте һәм «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә, шушы карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, 2020 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31

декабренә кадәр 2020-2024 елларга календарь буенча бүленгән аерым тарифлар билгеләргә.

3. Үзенә карата электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә тарифлар территориаль челтәр оешмасы эшчәнлеген дәвамлы җайга салу параметрлары нигезендә билгеләнә торган «Нижнекамскшина» гавами акционерлык җәмгыяте өчен, шушы карарның 3 нче кушымтасына туры китереп, 2020-2024 елларга озак сроклы җайга салу параметрлары билгеләргә.

4. Әлеге карарның 3 нче кушымтасына туры китереп, «Нижнекамскшина» гавами акционерлык җәмгыятенең 2020-2024 еллар кирәкле тулай керемен (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча) билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын башкаручы Л.П.Борисова

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-5/э карарына 1 нче кушымта

Нигездә бер генә кулланучыга хезмәт күрсәтүче челтәр оешмалары өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2020 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән бәяләр (тарифлар)

| т/с | Электр энергиясеннән (куәтеннән) файдаланучыларның тариф төркемнәре | Үлчәү берәмлеге | Ел | 1 яртыеллык | 2 яртыеллык |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| «Нижнекамскшина» гавами акционерлык җәмгыятенең территориаль челтәр оешмалары өчен монокулланучы («Түбән Кама бөтенметалл-кордлы шиннар заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте) тарафыннан түләнә торган тарифлар | | | | | |
| 1.1 | Ике ставкалы тариф | | | | |
| 1.1.1 | - электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | сум/МВт·ай. | 2020 | 34 513,73 | 34 513,73 |
| | | | 2021 | 35 513,73 | 35 513,73 |
| | | | 2022 | 36 257,96 | 36 257,96 |
| | | | 2023 | 37 169,51 | 37 169,51 |
| | | | 2024 | 38 108,41 | 38 108,41 |
| 1.1.2 | - электр челтәрләрендәге технологик сарыфлар (югалтулар) өчен түләү ставкасы | сум/МВт·сәг | 2020 | 0 | 0 |
| | | | 2021 | 0 | 0 |
| | | | 2022 | 0 | 0 |
| | | | 2023 | 0 | 0 |
| | | | 2024 | 0 | 0 |
| 1.2 | Бер ставкалы тариф | сум/кВт·сәг | 2020 | 0,05110 | 0,05110 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2021 | 0,05237 | 0,05237 |
| | | | 2022 | 0,05368 | 0,05368 |
| | | | 2023 | 0,05503 | 0,05503 |
| | | | 2024 | 0,05642 | 0,05642 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-5/э карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә 2020 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр календарь чорларына бүленгән аерым тарифлар

| т/с | Челтәр оешмаларының аталышы | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1. | "Нижнекамскшина" гавами акционерлык җәмгыяте – "Челтәр компаниясе" ачык акционерлык җәмгыяте | 2020 | 34 513,73 | 0 | 0,05110 | 34 513,73 | 0 | 0,05110 |
| | | 2021 | 35 513,73 | 0 | 0,05237 | 35 513,73 | 0 | 0,05237 |
| | | 2022 | 36 257,96 | 0 | 0,05368 | 36 257,96 | 0 | 0,05368 |
| | | 2023 | 37 169,51 | 0 | 0,05503 | 37 169,51 | 0 | 0,05503 |
| | | 2024 | 38 108,41 | 0 | 0,05642 | 38 108,41 | 0 | 0,05642 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-5/э карарына 3 нче кушымта

Үзенә карата электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә тарифлар территориаль челтәр оешмалары эшчәнлеген озак сроклы җайга салу параметрлары нигезендә билгеләнә торган территориаль челтәр оешмалары өчен 2020-2024 елларга озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Контроль дәге чыгымнарның база дәрәҗәсе | Контрольдә тотылырга тиешле чыгымнарның нәтиҗәлелек индексы | Активлар саны буенча контрольдәге чыгымнарның сыгылмалылык коэффициенты | Электр челтәрләре аша тапшырганда электр энергиясен югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясен тапшыру ноктасына тапшыруны туктатуның уртача дәвамлылыгы күрсәткече | Электр энергиясен тапшыру ноктасына тапшыруны туктатуның уртача ешлыгы күрсәткече | Күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфат дәрәҗәсе күрсәткече |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | млн сум | % | % | % | сәгать | данә | |
| 1 | "Нижнекамскшина" халыкка ачык акционерлык җәмгыяте | 2020 | 3130,7 | 3 | 75 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | | 2021 | X | 3 | 75 | X | 0 | 0 | 0 |
| | | 2022 | X | 3 | 75 | X | 0 | 0 | 0 |
| | | 2023 | X | 3 | 75 | X | 0 | 0 | 0 |
| | | 2024 | X | 3 | 75 | X | 0 | 0 | 0 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 11.12.2019
№ 3-5/э карарына 4 нче кушымта

2020-2024 елларга «Нижнекамскшина» гавами акционерлык җәмгыятенең (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча) кирәкле тулай кереме

| т/с | Татарстан Республикасында нигездә бер кулланучыга хезмәт күрсәтүче челтәр оешмасы исеме | Ел | Өстенлекле рәвештә бер генә кулланучыга хезмәт күрсәтүче челтәр оешмалары өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә бәяләр (тарифлар) раслаганда (хисаплаганда) исәпкә алынган челтәр оешмасының сарыфларын исәпкә алмаган КЗТ |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1 | "Нижнекамскшина" халыкка ачык акционерлык җәмгыяте | 2020 | 4 817,98 |
| | | 2021 | 4 937,92 |
| | | 2022 | 5 061,47 |
| | | 2023 | 5 188,72 |
| | | 2024 | 5 319,78 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге